| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
| --- | --- | --- |

| **ПРИКАЗ**<br>26.05.2026 | Казан ш. | **БОЕРЫК**<br>№01-05/86- пр |
| --- | --- | --- |

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 14 февралендәге 01-05/60-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 01.03.2022 ел, №01-05/68-пр, 05.10.2022 ел, №01-05/225-пр, 01.03.2023 ел, №01-05/61-пр, 25.08.2023 ел, №01-05/170-пр, 30.01.2024 ел, №01-05/21-пр, 26.03.2024 ел, №01-05/85-пр, 19.07.2024 ел, №01-05/191-пр, 22.11.2024 ел, №01-05/291-пр, 15.04.2025 ел, №01-05/80-пр, 05.11.2025 ел, №01-05/253-пр, 03.03.2026 ел, №01-05/56-пр боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Комиссия Идарә боерыгы белән төзелә, комиссиянең составы һәм аның эш тәртибе әлеге боерык белән раслана, комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре

билгеләп куела һәм комиссиянең башка әгъзалары билгеләнә.

Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

7 пунктның «а» пунктчасында «(комиссия рәисе),» сүзләреннән соң «Идарәдә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче зат (комиссия рәисе урынбасары)» сүзләрен өстәргә;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге Нигезләмәнең 7 пунктының «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 8 пунктында аталган затлар комиссия составына билгеләнгән тәртиптә, Идарә башлыгы гарызнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары белән, Идарә каршындагы Иҗтимагый совет, Идарәдәге ветераннарның иҗтимагый оешмасы, билгеләнгән тәртиптә Идарәдә гамәлдә булган профсоюз оешмасы белән килештереп кертелә.»;

15 пунктның «а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;»;

21 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәгә туры китереп, дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;».

Җитәкче А.Ш. Борһанов